БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

7 август 2024 ел №270

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл җирлекләренең генераль планны әзерләү зарурлыгы булмау турында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының кайбер авыл җирлекләре территориясендә әлеге җирлек территорияләреннән файдалануны үзгәртү күздә тотылмавына һәм социаль-икътисадый үсеш стратегияләренең шулай ук Россия Федерациясен территориаль планлаштыру документлары, Россия Федерациясе субъектын территориаль планлаштыру документлары, Балтач муниципаль районының территориаль планлаштыру документлары белән раслануына бәйле рәвештә федераль һәм региональ әһәмияттәге объектларны, муниципаль районның җирле әһәмияттәге объектларын әлеге җирлекләр территориясендә урнаштыру каралмавына бәйле рәвештә һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар кылды:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының түбәндәге авыл җирлекләрендә 2024 елның «31» декабренә кадәр генераль планны эшләүнең кирәк булмавын танырга:

- Шеңшеңәр авыл җирлеге;
- Карадуган авыл җирлеге.

2. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына Татарстан Республикасының 2023 елның 23 декабрендәге «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 131-ТРЗ номерлы Законы нигезендә 1 пунктта күрсәтелгән авыл җирлекләрендә җирдән файдалану кагыйдәләре һәм төзелеш проектын әзерләү турында карар кабул итү тәкъдиме белән Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына мөрәҗәгать итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайты аша (baltasi. tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Балтач муниципаль район башлыгы урынбасары,
Балтач Район Советы рәисе урынбасары Н.Н.Сабиржанов